# ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мажын авыл җирлегенең Богодаровка торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

25.11.2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль закон Федераль законының 25.1, 56 статьялары нигезендә,«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән,"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мажын авыл җирлегенең Богодаровка торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар жыенын билгеләү турында"Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгының 12.11.2024 ел № 11 карары нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлегенең Богодаровка торак пунктында жыен

**КАРАР ЧЫГАРА:**

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Яңа Мажын авыл җирлеге Богодаровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Богодаровка торак пунктында Озерная урамы буенча торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү));

Гражданнар жыены нәтиҗәләрен Яңа Мажын авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык жыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгы _______________ И.А.Колбин